БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 июль 2019 ел № 196

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 17 декабрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2019 елга, 2020-2021 еллар план чорына бюджеты турында» 158 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 17 декабрендәге “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2019 елга, 2020-2021 еллар план чорына бюджеты турында” 158 номерлы карарына (15.03.2019, 29.04.2019 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2019 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең гомуми күләме 914036,18 мең сум;

2) Балтач муниципаль районы бюджетының гомуми күләме 941997,45 мең сум.

3) Балтач муниципаль районы бюджеты дефицитының күләме 27961,27 мең сум.».

1.2. Карарның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:

- 2019 елда әлеге карарга 18 нче кушымта нигезендә 619355,17 мең сум күләмендә;

- 2020 елда 521871,5 мең сум һәм 2021 елда әлеге карарга 19 нчы кушымта нигезендә 525310,20 мең сум күләмендә.».

1.3. Карарның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2019 елга Балтач муниципаль районының Юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләмен 14557,32 мең сум күләмендә расларга, 2020 елга 13600 мең сум, 2021 елга 14100 мең сум күләмендә, аларны Балтач муниципаль

районының 2019, 2020 һәм 2021 елларга гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре Программасы чараларын тормышка ашыруга җибәрергә.

1.4. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 17 декабрендәге “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2019 елга, 2020-2021 еллар план чорына бюджеты турында” 158 номерлы карарының №1,№3,№6,№8,№10,№18,№20 кушымталарын әлеге карарга №1,№2,№3,№4,№5,№6,№7 кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин